ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АЕШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423761, Аешавылы, Ленин ур., 34б йорт.

СОВЕТ АИШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

423761, село Аишево, ул. Ленина, дом 34б.

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 16** **от 03.07.2020**

**Актаныш муниципаль районы Аеш авыл җирлегенең кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында**

Норматив хокукый актларны гамәлдәге кануннарга туры китерү максатларында Актаныш муниципаль районының Аеш авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Актаныш муниципаль районының Аеш авыл җирлеге Советының «Актаныш муниципаль районының Аеш авыл җирлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы муниципаль вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында» 10.09.2007ел №2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а. 1 нче кушымтаның 9 пунктындагы 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «5) индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ, моңа хезмәт шартнамәсенең (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклары керми;».

2. Актаныш муниципаль районының Аеш авыл җирлеге Советының «Актаныш муниципаль районы Аеш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә яңа редакциядә» 07.09.2017ел №24 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а. Нигезләмәләнең 3.3 пунктының 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «6) индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ, моңа хезмәт шартнамәсенең (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклары керми;».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Аеш авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Аеш авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Совет рәисе
Актаныш муниципаль районы
Аеш авыл җирлеге Ялилов Д.А.